Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

Азнакай шәһәре №58-10 «22» май 2026 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2023 елның 12 октябрендәге 165-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай район Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай район Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2023 елның 12 октябрендәге 165-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай район Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай район Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутатның вәкаләтләре чоры «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнә.»;

- 3 статьяның 1 пунктының 11, 12 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта;

12) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 номерлы Федераль законнарда һәм башка федераль законнарда каралган башка очракларда.»;

- 3 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен « Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

- 17 статьяның 1 пунктының 9, 10 пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«9) "9) дәүләт һәм закон белән саклана торган башка серне сакларга, шулай ук гражданнарның шәхси тормышына, намусына һәм абруена кагылышлы, депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә аларга билгеле булган белешмәләрне фаш итмәскә;

10) ел саен, хисап финанс елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне гамәлдәге законнар нигезендә тапшырырга тиеш.

- 18 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында башка вазыйфалар биләргә;

2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Бу чакта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Россия Федерациясе законнарында яисә федераль дәүләт хакимияте органнарының чит дәүләт органнары, халыкара яисә чит ил оешмалары белән үзара нигездә төзелгән шартнамәләрендә башкасы каралмаган булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый.;

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә, Россия Федерациясе законнарында яисә дәүләт хакимиятенең федераль органнарының чит дәүләтләрнең дәүләт органнары, халыкара яисә чит ил оешмалары белән үзара бәйләнешендә башкасы каралмаган булса, чит ил коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларының һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләренең башка органнары составына керергә.».

2. Әлеге карарны түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М. З. Шәйдуллин